**БИШЕНЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**КАРАРЫ**

2026 ел, 4 февраль №31

**Апас муниципаль районы авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә һәм Апас муниципаль районы чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән читтә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2021 елның 4 октябрендәге 71 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районы авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә һәм Апас муниципаль районы чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән читтә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.4.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында контрольдә тотылучы затка ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча» Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында " 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә .".

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны агросәнәгать комплексы, экологик иминлек һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы башлыгы-**
**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы Советы Рәисе А.Г.Җиһаншин**